Җир йөзендә тынычлык, дуслык,мәрхәмәтлелек,гаделлек булсын!

# Чишмә башы

## Өчиле төп гомуми белем мәктәбе




Хөрмәтле ир-егетләребез!

Сезне Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз! Һәрвакыт шулай, авырлыклардан курыкмаучы, авыр минутларда үз җилкәсен куярга әзер торучы чын ир-ат булып калыгыз. Сәламәтлек ышанычлы юлдашыгыз булсын! Саф мәхәббәт, ныклы гаилә телибез. Максатларыгызга ирешү, хыялларыгызны тормышка ашыру юлында бернинди киртәләр һәм кыенлыклар очрамасын. Бәйрәмегез белән!

**Туган илне саклау ирләр эше**

**Сез акларга тиеш өметне.**

**Мактау белән искә ала һәркем**

**Ил сакчысы дигән егетне…**

**Сез булганга имин булып ата таңнар,**

**Тыныч-матур тормыш белән үтә айлар.**

**Бәйрәмегез котлы булсын, ир-егетләр,**

**Мәңге тыныч, имин торсын җирләр-күкләр.**

**23 февраль –**
**Ватанны саклаучылар көне!**

1918 елның 15 гыйнварендә СССРның Халык комиссарлары Советы Эшче-Крестьяннар Кызыл Армиясен төзү турында декрет игълан итә. Әлеге декрет 20 январьда бөтен халыкка игълан ителә һәм шул көннән башлап Кызыл Армия сафларына кабул итү башлана. Кызыл Армия сафларына ул вакытта кәгазьдә генә кабул ителәләр. Чын хәрби армия әле булмый. Шул ук елның 23 февраль көнне Халык комиссарлары Советының «Социалистическое отечество в опасности» ("Социалистик ватан куркыныч астында") чакыруы басылып чыга. Әлеге чакыру һәркемне кулга корал алып революцияне саклап калырга чакыра.

Шул елларда Советлар Союзы күп кенә илләр белән Тынычлык турында килешү төзи алган, сугышлар туктатылган. Әлеге килешүләрнең күбесе белән тарих битләреннән танышып була.

Кызыл армия һәм флот көне исә 1922 елдан башлап бәйрәм ителә башлаган. Бүген әлеге бәйрәм Ватанны саклаучылар көне дип игълан ителә.

Ватанны саклау - бүгенге көндә һәркемнең бурычы. Балаларда иң беренче патриотик тәрбия, Ватанны саклау хисен укытучылар уята һәм ныгыта. Ватанны саклау өчен аермачык кулга корал да тотарга кирәкми. Моның өчен кеше гыйлемле булырга, тарих сабакларына төшенергә, киләчәкне акыл белән кора белергә тиеш. Димәк, әлеге бәйрәм өлешчә бөтен укытучыларның да бәйрәме.

Ватанын яраткан һәм аның киләчәге өчен көч сарыф иткән һәр кешене әлеге бәйрәм белән тәбрик итәбез. Туган ил, туган тел, туган өй сүзләре һәрвакытта да күңелләрдә иң изгеләрдән, иң кыйммәтлеләрдән булсын. Бары тик үз туган иле, үз туган теле, үз гаиләсе белән горур кешеләр генә башка илләрнең, башка телләрнең, башка гаиләләрнең кадерен белә ала. Үз туган илебезне, үз туган телебезне онытмыйк, кадерен белик, Ватаныбыз сагында булыйк!



**И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!**

Тук

# 21 февраль –
# Халыкара туган тел көне

*Дөньяда иң-иң матур ил –*
*Ул минем туган илем.*
*Дөньяда иң-иң матур тел –*
*Ул минем туган телем.*



## Татар халык мәкальләре

- *Теле татлының – дусты күп.*
- *Татлы тел - тимер капканы да ачар.*
- *Телеңне тыйсаң, тыныч булырсың.*
- *Тел ташны эретә.*
- *Әдәп башы – тел.*
- *Инсафлының – теле саф.*

Тел кешенең кемлеген аңлата

Иң татлы тел- туган тел,
Анаң сөйләп торган тел.

Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.

## Шигырь сөйлим туган телемдә

**“Туган телем”**

Үз телемдә шигырь укыйм,
Үз телемдә сөйли алам.
Туган җирем, туган илем,
Мин бит синнән илһам алам.
Хәтта кошның да туган теле бар,
Теле булганның гына иле бар.
Бабаларымның иң зур мирасы,
Чиксез галәмнең гүя моңы син.
Яшә мәңгегә
И, туган телем,
Былбыл моңыдай.
И, матур телем.

*Тел ул – буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк мөкатдәс бер мирас.
Тел, ниһаять, туган ил, туган җир ул.
*Х. Сәрьян*

*Тел ул – буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән һәм күчәчәк мөкатдәс бер мирас.
Тел, ниһаять, туган ил, туган җир ул.
*Х. Сәрьян*

## ВИКТОРИНА

1. Бу шигырь юлларының авторы кем?
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!
2. Татар теле кайчан Татарстан Республикасының дәүләт теле дип игълан телде?
3. Туган тел көне ничәнче елдан билгеләп үтелә башлады?
4. Күп телләр белүчене ничек атыйлар?
5. Татар теле Россиядә рус теленнән кала ничәнче урында тора?
6. Бүгенге көндә дөньяда ничә меңнән артык телдә сөйләшәләр?



### “ТУГАН ТЕЛЕМӘ”

Әйтә алмыйм әле - ул сүзләрдән
Аз булса да дөнья үзгәрерме?
Тик югалтмам, туган телем, синнән
Алып торган асыл сүзләремне.
(Роберт Миңнуллин)



# Алар-горурлыгыбыз



**Габдрахманов Фидаил Фирдинат улы**

2000 нче елның 12 июлендә Арча районы Югары Бирәзә авылында туа. Әтисе , Габдрахманов Фирдинат Тәфкил улы, Фидаилгә 14 яшь вакытта вафат була. Әнисе, Габдрахманова Эльмира Зиннәтулла кызы, лаеклы ялда. Фидаил гаиләдә дүртенче бала.

Фидаил 2007 елның 1 сентябрендә Арча районы Югары Бирәзә авылының башлангыч мәктәбенә, 2011 елны Өчиле төп гомуми белем мәктәбенең 5 сыйныфына укырга керә. 2016 елда мәктәпне уңышлы тәмамлап, 2016-2019 елларда Үрнәк аграр-сәнәгать һөнәр көллиятенең Арча филиалында белем ала. Ташчы һәм эретеп ябыштыручы һөнәрләрен үзләштерә.

Егет 2019 - 2020 нчы елларда армия сафларына алына. Иваново шәһәренең һава-десант гаскәрләрендә хезмәт итә. 2020 елның декабрендә “ТехноАрск”ширкәтенә эшкә урнаша.

Фидаил , 2022 елның 26 сентябрендә мобилизацияләнеп, махсус хәрби операция барган зонага китә (29660 нчы хәрби часть,1234 полк, 1 батальон, 2 рота, рядовой).

2023 елның 24 октябрендә миномет утына эләгә һәм каты яралана, Мәскәүдә хәрби госпитальдә дәвалана. Сәламәтлегенә зур зыян килү сәбәпле, хезмәттән азат ителә.



**Шәмсетдинов Салават Марат улы**

1997 нче елның 11 январенда Арча районы Югары Бирәзә авылында туа. Әтисе, Шамсетдинов Марат Ринат улы, шофер булып эшли. Әнисе - Шәмсетдинова Фирдисә Филсур кызы. Салават гаиләдә беренче бала.

Шәмсетдинов 2004 елның 1 сентябрендә Арча районы Югары Бирәзә авылының башлангыч мәктәбенә, 2008 елны Өчиле төп гомуми белем мәктәбенең 5 сыйныфына укырга керә. 2013 елны мәктәпне уңышлы тәмамлап, 2013-2017 елларда Арча педагогия көллиятенең физкультура бүлегендә белем ала.

Егет 2017 - 2018 нчы елларда армия сафларына алына. Саратов шәһәрендә РВСН гаскәрендә хезмәт итә. Хәрби хезмәттән кайткач, Казан шәһәрендә шәхси оешмада хезмәт куя.

Салават , 2022 елның 26 сентябрендә мобилизацияләнеп, махсус хәрби операция барган зонага китә (29660 нчы хәрби часть,1234 полк, 1 батальон, 2 рота, рядовой). “За отвагу” медале белән бүләкләнә. Бүгенге көндә хезмәтен дәвам итә.



**Зыятов Илһам Зөфәр улы**

1991 нче елның 14 мартында Арча районы Чиканас авылында туа. Әтисе дә, әнисе дә вафат.

Илһам 1997 елның 1 сентябрендә Арча районы Чиканас авылының башлангыч мәктәбенә, 2001 елны Өчиле урта мәктәбенең 5 сыйныфына укырга керә. 2008 елны, мәктәпне тәмамлап, 2008-2009 елларда Үрнәк аграр-сәнәгать һөнәр көллиятенең Арча филиалында белем ала. 2009-2010 нчы елларда хәрби хезмәттә була.

Армиядән кайткач, Илһам эшкә урнаша, Арча шәһәрендә “Магнит” кибетендә эшли.

Илһам , 2022 елның 26 сентябрендә мобилизацияләнеп, махсус хәрби операция барган зонага китә (33836 нчы хәрби часть, 621 полк, 1 батальон, 3 рота, рядовой). “За отвагу” , “За воинскую доблесть” медальләре белән бүләкләнә.



**Исламов Алмаз Илдус улы**

1995 нче елның 22 январенда Арча районы Күкчә Бирәзә авылында туган. Әтисе , Исламов Илдус Гыйлембай улы, бүгенге көндә вафат. Әнисе, Исламова Раузания Зәки кызы, Күкчә Бирәзә авылы клубында эшли. Алмаз гаиләдә беренче бала.

Исламов 2001 елның 1 сентябрендә Арча районы Күкчә Бирәзә авылының башлангыч мәктәбенә, 2005 елны Өчиле урта мәктәбенең 5 сыйныфына укырга керә. 2010 елны, мәктәпне уңышлы тәмамлап, 2010-2013 елларда Үрнәк аграр-сәнәгать һөнәр көллиятендә белем ала.Тракторист-машинист, эретеп-ябыштыручы һөнәрләрен үзләштерә.

Егет 2013 - 2014 нчы елларда армия сафларына алына. Саратов шәһәренең РХБЗ гаскәрендә хезмәт итә.

Алмаз , 2024 елның 19 июлендә контракт нигезендә , махсус хәрби операция барган зонага китә. Бүгенге көндә алгы сызыкта.